КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 апрель г.Казань № 406

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларында ачык хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарының һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларның хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарының һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча социаль-көнкүреш уңайлыгын оештыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарының һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча социаль-көнкүреш уңайлыгын оештыру белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Карарга теркәлгән Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеген расларга.

4. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары урнашкан урыннарда югарыда күрсәтелгән гражданнарны вакытлыча урнаштыру урыннарында су белән тәэмин итүне, туклануны, яшәү шартларын оештыруда санитария-эпидемиология күзәтчелеген тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән һәм вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктында (пунктларында) булган затларның исәбен алып бару һәм кушымта нигезендә форма буенча исемлекләрен формалаштыруны һәм әлеге исемлекләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Финанс белән тәэмин итү

чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары тарафыннан тотылган  Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган,  Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын  каплау максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына  федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында" 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары белән (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары) расланган  Финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары тарафыннан тотылган  Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы  территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган,  Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына  федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә  кушымта нигезендә форма буенча җыелма исемлекне төзүне, әлеге исемлекне Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерү һәм аны алга таба Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгына тапшыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итәргә.

7. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган,  Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез  массакүләм тәртиптә килгән  Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары урнашкан оешмаларның чыгымнарын кайтару вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында кешеләр тору көннәренең факттагы саныннан чыгып,  бер кешегә тәүлегенә вакытлыча урнаштыруга тәүлегенә 913 сумга кадәр һәм туклану өчен -  415 сумга кадәр чыгымнарны да кертеп, бер кешегә тәүлегенә 1 328 сум күләмендә башкарыла;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм тукландыру чыгымнарын кайтару Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

8. Бу карарның гамәле 2022 елның 18 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 30 апрель, 406 нчы
карары белән расланды

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китергә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Базасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешманың исеме |
|---|---|---|
| 1. | Казан шәһәре | Шәхси эшмәкәр Әбушахманова Гөлнара Рафаил кызы ("Икенче Йорт" кунакханәсе) |
| 2. | Казан шәһәре | «Кварт» ЯАҖ кунакханә-торак комплексы |
| 3. | Казан шәһәре | «Ливадия-Татарстан» шифаханәләр һөнәри берлекләренең дәвалау-профилактика шәхси учреждениесе |
| 4. | Казан шәһәре | "Экспресс" ҖЧҖ ("Экспресс» хостелы) |
| 5. | Зеленодольск муниципаль районы | «Васильевский» шифаханәләр һөнәри берлекләренең дәвалау-профилактика шәхси учреждениесе |
| 6. | Лаеш муниципаль районы | "Санта" шифаханәсе ҖЧҖ |
| 7. | Чаллы шәһәре | «Камазжилбыт» ЯАҖ |
| 8. | Чаллы шәһәре | «Жемчужина» шифаханәләр һөнәри берлекләренең дәвалау-профилактика шәхси учреждениесе |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 08 апрель, 332 нче
карарына кушымта

Форма

## Кичектергесез массаүләм рәвештә килгән һәм вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктында (пунктларында) булган затлар исемлеге

| Т/с | Гражданның (гражданлыгы булмаган затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | Туу датасы | Шәхесне таныклаучы документның сериясе һәм номеры | Гражданлыгы | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты адресы | Урнашу һәм туклану вакыты / тәмамлану датасы | Урнашу һәм туклану тәүлекләре саны | Урнаштыру/ туклану чыгымнары суммасы, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| Кирәкле бюджет ассигнованиеләре барлыгы | | | | | | | | |

Муниципаль берәмлекнең башкарма
комитеты җитәкчесе

______________________________________________
(имзасы, фамилиясе, инициаллары)

М.У.

_______________________________